ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский Бистәсе авылы,
422591

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.12.2019 №167

с. Введенская Слобода

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлегендә гражданнарның
үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнар җыеннарында 2019 елның 27 ноябрендә кабул ителгән 1,2,3 номерлы; 2019 елның 28 ноябрендә кабул ителгән 4,5 номерлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы

Д. В. Морозов

Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 2 декабрендәге
167нче номерлы карарына
1нче кушымта

**Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1.Бу тәртип Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 1 гыйнварыннан 31 мартына кадәр Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге территориясендә, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуга һәм тавыш бирүдә катнашуга карамастан, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан түләнә.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме җирле референдум карарында (гражданнар җыенында) билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнардан үзара салымнан алынган акчалары Введенский Бистәсе авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

7. Гражданнарның түләүләре физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыруга, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) гамәлгә ашыруга яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/. сылтама буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашырырга хокуклы оешмалар аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 2 декабрендәге
167нче номерлы карарына
2нче кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И. О. ______________________________________________

Адресы: ______________________________________________

Сезгә ____________________________нигезендә ____________________

вакытында кадәр ________________________чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр _________________ сум түбәндәге реквизитлар буенча____________________________________________ түләргә кирәк.

Алучының банк БИК ______________________________

Сч. № ______________________________

Алучының сч. № ____________________________________

ИНН ____________________________________

КПП ____________________________________

КБК ________________ ОКАТО______________

Түләү билгеләү ______________________________________________

Җитәкче __________________ ______________________________

(имза) (имзаны роасшифровкалау)

М. у.

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № __________________

______________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

бюджетына үзара салым буенча _________________ суммада бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И.О. ____________________________________

Адресы: ______________________________________________

Алган «__» ________________ 20__ ел___________________

( түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Аермалы кәгазь тутырыла һәм түләүчегә хәбәр шәхсән тапшырылса _______________ авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*